| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ**
«28» апрель 2023 ел

**КАРАР**
№ 73

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Карадуган авыл җирлеге Уставы белән Карадуган авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срок тәмамлангач яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан иткәч, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның барысы да мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның барысы да мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка кеше файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүче -физик зат гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада табылса;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срок тәмамланса;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок узса.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советының 21.10.2019 елның №119 «Бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм җирле салымнар буенча штрафларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарында үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының (baltasi.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыру юлы белән һәм торак пунктның махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге башлыгы Низамиев Шамил Вәкил улына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Карадуган авыл җирлеге башлыгы Ш.В.Низамиев